**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

(V чакырылыш)

V чакырылыш чираттан тыш утырыш
**КАРАРЫ**

«17» октябрь 2025 ел №12 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында»гы 07.10.2025 ел, № 9 карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»гы 30.04.2025 №15 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмә, «Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»гы 30.04.2025 елның 15 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында"гы Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 07.10.2025 елның 8 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында» 07.10.2025 елның 9 санлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс 2025 елның 7 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Урыссу

ш.т. б., Пушкин ур., 38 йорт адресы буенча урнашкан утырышлар залында үткәрергә.».

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарны Ютазы таңы («Ютазинская новь») вакытлы матбугат басмасында (ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык № 77-47613 07.12.2011, Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы З.В. Ильясов

Р.М. Якупов
2-42-05